КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 сентябрь г.Казань № 977

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 21 июнь, 484 нче карары белән расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 484 нче белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 1 ноябрь, 1035 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына

ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«транспорт чаралары (алга таба – ТЧ) – автомобиль техникасының барлык төрләре (җиңел автомобильләр, җиңел йөк транспорты, йөк автомобильләре, автобуслар, коммуналь техника, махсус билгеләнештәге автомобиль техникасын кертеп). Шул ук вакытта транспорт чаралары Россия Федерациясе территориясендә әйләнешкә чыгарылырга һәм теркәлергә, чыгарылыш елы агымдагы финанс елына кадәр 15 елдан да иртәрәк булмаска тиеш;»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башкарылган эшләрне ТЧ паспорты яки транспорт чарасын теркәү турында таныклык күчермәләре белән раслап, кертелгән үзгәрешләрне һәм башкарылган эшләр актларын теркәп, субсидия бирелгән елга кадәрге елның 1 гыйнварыннан кимендә 10 берәмлек транспорт чарасын яңадан җиһазландыру тәҗрибәсен раслый торган документлар;»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Сайлап алу, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына, таләпләренә туры килүеннән һәм тәкъдимнәр (заявкалар) керү чиратыннан чыгып, тәкъдимнәр (заявкалар) нигезендә тәкъдимнәрне (заявкаларны) сратып алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, тәкъдимнәр (заявкалар) бирелә башланган датага кадәрге бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр хакында мәгълүмат бирелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) бирә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 19 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Нигезләмәнең 5 һәм 8 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары, бу Тәртипнең 10 пункты нигезендә тәкъдимнәр (заявкалар) бирү тәртибе һәм тәкъдимнәр (заявкалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире алу тәртибе, тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару (шул исәптән тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, тәкъдимнәргә (заявкаларга) үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 13 пунктлары нигезендә сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә имза кую вакыты;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

7 пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пунктының кысылган табигый газ белән эшләү өчен автомобильләрне яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрүгә яраклылык сертификаты һәм субсидия бирелгән елга кадәрге елның 1 гыйнварыннан кимендә ун берәмлек транспорт чарасын яңадан җиһазландыру тәҗрибәсе булуын раслый торган документлар;»;

8 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кулланыла торган газ баллоны җайланмасы, аның компонентлары, комплектлау әйберләре һәм сайлап алуда катнашучы тарафыннан башкарыла торган транспорт чарасын яңадан җиһазландыру эшләре Таможня берлегенең «Көпчәкле транспорт чараларының куркынычсызлыгы турында» техник регламентына (Федераль кагыйдәләр нигезендә) туры килә;»;

10 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә дә, кәгазь чыганакта да бирергә хокуклы. Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә бирү «ГБО.РФ газ-мотор ягулыгы базарының бердәм платформасы» (алга таба – ГБО платформасы) сервисының рәсми сайты аша гамәлгә ашырыла. Сайлап алуда катнашучы ГБО платформасында катнашу өчен заявка бирә. Тәкъдимне (заявканы) электрон төрдә тапшырганда теркәлә торган документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан аларның сканерланган күчермәләре рәвешендә тапшырылырга тиеш. Техник сәбәпләр аркасында ГБО платформасы аша тәкъдим (заявка) бирү мөмкин булмаганда, сайлап алуда катнашучы документларның сканерланган, zip архивында булдырылган күчермәләрен gmt.ppto@mail.ru адресы буенча җибәрә.

Сайлап алуда катнашу өчен тәкъдим (заявка) электрон төрдә бирелгәндә сайлап алуда катнашучы вәкаләтле органга түбәндәге документлар белән тәкъдим (заявка) бирә:»;

егерме алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (кирәк булганда).»;

егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуда катнашучы тарафыннан Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (кирәк булганда) бирелмәсә, вәкаләтле орган әлеге белешмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән яки ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала.»;

утызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктта:

егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (кирәк булганда).»;

егерме сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуда катнашучы тарафыннан Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (кирәк булганда) бирелмәсә, вәкаләтле орган әлеге белешмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән яки ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала.»;

16 пунктның өченче абзацы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү турындагы килешүдә субсидия күләме, кире кайтару максаты белән субсидия бирелә торган, алынып бетмәгән керемнәр юнәлеше, субсидия күчерү тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре, субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары, вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан бу Тәртипнең 23 пунктында каралган тикшерүләрне гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы, аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда кире кайтару шартлары, бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән, моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары вәкаләтле органга субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмый торган итеп киметелгән очракта, субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешүгә ирешеп булмаганда субсидия бирү турындагы килешүне өзү турында шарт.»;

18 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия күләме мотор ягулыгы буларак табигый газ (метан) куллану өчен транспорт чарасын яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы субсидия алучы тарафыннан транспорт чарасы хуҗасына Федераль кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасы нигезендә һәм бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән иң күбе максималь күләмдә бирелгән ташлама күләменә тигез итеп билгеләнә.»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр мотор ягулыгы буларак табигый газ (метан) куллану өчен яңадан җиһазландырылган транспорт чарасы хуҗасы (шул исәптән лизинг шартнамәсе нигезендә) физик зат яки юридик зат – кече яки урта эшмәкәрлек субъекты булса, бу

Тәртипнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән субсидиянең максималь күләме 2 коэффициентка тапкырлана.»;

20 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Субсидия алучы вәкаләтле органга Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Вәкаләтле орган субсидия алучыларның субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Вәкаләтле орган, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглауны гамәлгә ашыра.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Субсидия бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту һәм аларны бозган өчен җавап бирү вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Тәртипнең 4 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. 2023 елның 1 гыйнварына кадәр Тәртипнең 5 пунктындагы өченче абзацы, 10 пунктындагы егерме беренче абзацы, 11 пунктындагы егерме икенче абзацы, 3 нче кушымтасындагы икенче абзацы гамәлдә булуны туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы илле дүртенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 10 сентябрь, 977 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 484 нче белән расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе таләпләре нигезендә үткәрелгән эшләр турында
гарантия хаты

_______________________________________________________________ йөзендә,
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

________________________________________________________________________________
(индивидуаль эшмәкәрнең устав реквизитлары, төп дәүләт теркәү номеры таныклыгы,
_______________________________________________________________ нигезендә эш итүче
ышанычнамәсе реквизитлары)

________________________________________________________________________________
(юридик затның исеме, индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

моның белән яңадан җиһазландыру пункты тарафыннан тәкъдимдә (заявкада) күрсәтелгән транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшләрен газ баллоны

җайланмасына, аның компонентларына һәм комплектлау әйберләренә карата түбәндәге таләпләр, шулай ук мотор ягулыгы буларак табигый газ куллануга транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшләрен башкаруга карата түбәндәге таләпләр нигезендә башкаруныраслый һәм гарантия бирә, ягъни:

урнаштырылган газ баллоны җайланмасының тибы Берләшкән Милләтләр Оешмасына караган Европа икътисадый комиссиясенең « II. Двигательләрендә кысылган табигый газ кулланыла торган механик транспорт чараларына урнаштыру өчен билгеләнгән махсус модификацияләнгән кысылган табигый газ системаларын рәсми раслауга кагылышлы бертөрле күрсәтмәләр» 2003 елның 30 октябрендәге 115 номерлы кагыйдәләренең II өлеше таләпләренә туры килә, бу тиешле сертификат белән раслана;

кулланылган җайланма элементлары (компонентлары) Берләшкән Милләтләр Оешмасына караган Европа икътисадый комиссиясенең «I. Двигательләре кысылган табигый газ һәм/яки сыекландырылган табигый газ белән эшли торган механик транспорт чараларының махсус җайланма элементлары; II. Транспорт чараларының двигательләрендә кысылган табигый газ һәм/яки сыекландырылган табигый газ куллану өчен рәсми расланган типтагы махсус җайланма элементларын урнаштыруга карата транспорт чараларын рәсми раслауга кагылышлы бертөрле күрсәтмәләр» 2000 елның 28 декабрендәге 110 ПО номерлы кагыйдәләре таләпләренә туры килә, бу тиешле сертификат белән раслана;

урнаштырылган җайланма яңа (элек кулланылышта булмаган) булырга тиеш;

урнаштырылган газ баллоны агымдагы елның 1 гыйнварына кадәр 18 айдан да иртәрәк булмаган вакытта чыгарылырга һәм саклау җайланмасы булган автомат вентиль белән җиһазландырылырга тиеш;

үз илебездә җитештерелгән, урнаштырылган газ баллоны: I тип баллон өчен – 2023 елдан башлап, II тип баллон өчен – 2024 елдан башлап, III тип баллон өчен – 2020 елдан башлап, бу баллон паспорты белән раслана;

кулланыла торган газ баллоны җайланмасы, аның компонетлары, комплектлау әйберләре һәм яңадан җиһазландыру пункты тарафыннан транспорт чарасын яңадан җиһазландыру буенча башкарыла торган эшләр Таможня берлегенең «Көпчәкле транспорт чараларының куркынычсызлыгы турында» техник регламентына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карарына һәм һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына туры килә.

Сайлап алуда катнашучы ___________________ _________________
______________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда) 20___ ел, «___» __________

______________________________________